Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Көчек авыл җирлегенең Рус Шаршадысы торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2019 ел, 26 ноябрь** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге Рус Шаршадысы торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Көчек авыл җирлеге Рус Шаршадысы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
- Рус Шаршадасы авылы суэтем башнясын санитар саклау йөзеннән койма белән әйләндереп алу.
-Кеше тормышына һәм сәламәтлегенә яный торган корыган агачларны кисү.
-Рус Шаршадасы авылы Кыр урамы юлларын кыш көне кардан чистарту.
3. Гражданнарның җыен нәтиҗәләрен Көчек авыл җирлеге мәгълүмати стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы Р.Ә. НУРМӨХӘМӘТОВ